Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз бишенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

19 октябрь, 2023 ел

№ 263

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, 2023 елның 11 октябрендәге гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендәге 268 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең Генераль планына, электрон чыганактагы кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтына (https://fgistp.economy.gov.ru/) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында әлеге карарны урнаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы — И.М. Кашапов